**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«25» октябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Чуаш Тимерлеге авылы гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Чуаш Тимерлеге авылы территориясендә теркәлгән Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан, 1 группа инвалидлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- МТЗ-82.1 тракторы һәм асылмалы җиһазлар сатып алуга;

- Чуваш Тимерлеге авылы торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау һәм таш түшәү.

Халык җыенында рәислек итүче: В.И. Гаврилов

Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов